| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.08.2020 Казан шәһәре № 72-52/тп-2020

«Алексеевскводоканал» ачык акционерлык җәмгыятенең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтырган (технологик ялгаган) очракта аерым тәртиптә түләү билгеләнә торган мөрәҗәгать итүчеләр объектларының тоташтырыла (ялгана) торган йөкләнеш күләмен билгеләү турында» 2017 елның 22 апрелендәге 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, «Алексеевскводоканал» ачык акционерлык җәмгыятенең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 05.08.2020
№72-52/тп-2020 карарына кушымта

«Алексеевскводоканал» ачык акционерлык җәмгыятенең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен тарифлар

| № т/с | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тоташтыруга тарифлар (НДС исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоташтырыла торган йөкләнешкә тарифның база ставкасы | мең сум/тәүлегенә куб.метр | 0,7195 |
| 2. | Челтәрләр озынлыгына тарифның база ставкасы | мең сум/км | 2 764,30 |
| 3. | Челтәрләрнең диаметрына карап, тарифны дифференциацияләү коэффициенты: | | |
| 3.1. | диаметры 40 мм һәм азрак | - | 0,61 |
| 3.2. | диаметры 40 мм югары, 70 мм кадәр | - | 0,61 |
| 3.3. | диаметры 70 мм югары, 100 мм кадәр | - | 0,63 |
| 3.4. | диаметры 100 мм югары, 150 мм кадәр | - | - |
| 3.5. | диаметры 150 мм югары, 200 мм кадәр | - | - |
| 3.6. | диаметры 200 мм югары, 250 мм кадәр | - | - |
| 3.7. | диаметры 250 мм һәм аннан да югары | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге